**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Сугышлы авыл җирлегенең Сугышлы торак пунктында гражданнар җыены**
**КАРАРЫ**

2023 елның 18 ноябре №2

2024 елда Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Сугышлы авыл җирлегенең Сугышлы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Сугышлы авыл җирлеге Сугышлы торак пункты гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2024 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Сугышлы авыл җирлеге Сугышлы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, , 1 төркем инвалидлар; Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннары, хәрби хезмәт үтүче хәрбиләр; көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш,, һәр балигъ булган кешедән 500 9Биш йөз) сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:
а) торак пункт чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, су чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру:

-Сугышлы торак пунктында, Насосная урамында яңа су белән тәэмин итү линияләрен салу буенча эшләр;
б) җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, инвалидлар өчен социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларына һәм күрсәтелә торган хезмәтләргә ирешү мөмкинлеген тәэмин итү таләпләрен үтәү, җирлек территориясен төзекләндерүне күрсәтелгән Кагыйдәләргә ярашлы оештыру, төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру:
- Сугышлы торак пунктында (Үзәк урамы,Гафиятуллин урамы, Гагарин урамы,Насос урамы, Хәлиуллин урамы)урамнарны яктыртуга техник хезмәт күрсәтү;
- территориядә механикалаштырылган һәм кул белән үлән чабу буенча хезмәтләр өчен түләү, иске авария хәлендәге агачларны кисү (килешү буенча эш өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу);
в) торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
Сугышлы торак пунктында юлларны кардан чистарту (Үзәк урам, Гафиятуллин урамы, Гагарин урамы, Насос урамы, Хәлиуллин урамы) сораулары буенча карарны кабул ителгән дип таныргa.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Сугышлы авылы, Үзәк урам, 27 йорт адресы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы
«Сугышлы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы А.П.Зыятдинова